| | | |
|---|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 февраль 2014 ел Казан шәһәре **Карар №** 10-5/кс

***Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәте күрсәтүгә тарифны билгеләү турында***

“Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында” 30 декабрь, 2004 ел, № 210-ФЗ Федераль законга, “Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя кую нигезләре һәм тарифларны, өстәмәләрне һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында” 14 июль, 2008 ел, № 520 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь, 2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга № 1 кушымта нигезендә, коммуналь комплекс оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәте күрсәтүгә тарифны календарь бүленеш нигезендә билгеләргә.
2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф 2014 елның 1 апреленнән 2017 елның 31 мартына кадәр үз көчендә була.
3. Бу карарның 2 пунктында күрсәтелгән тарифның гамәлдә булу чорына, № 2 кушымта нигезендә, каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү өлкәсендә производство программаларының төп күрсәткечләрен килештерергә.
4. Әлеге карарның 1нче кушымтасында күрсәтелгән коммуналь комплекс оешмаларына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 30 декабрь, 2009 ел, № 1140 карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифны билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.
5. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәте күрсәтүгә бу карарда билгеләнгән тариф “Коммуналь комплекс оешмалары товарларының һәм хезмәтләр күрсәтүләренең кулланучылар өчен куллану мөмкинлеге критерийлары системасын билгеләү турында” 27 февраль, 2012 ел, № 45 Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты боерыгы белән расланган коммуналь комплекс оешмалары товарларының һәм хезмәтләр күрсәтүләренең кулланучылар өчен куллану мөмкинлеге критерийларына туры килә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисе вазыйфаларын
башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14 февраль 2014 ел № 10-5/кс
карарына 1нче кушымта

# Коммуналь комплекс оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәте күрсәтүгә календарь бүленеш нигезендәге тарифлары

| № п/п | Муниципаль берәмлек, коммуналь комплексы оешма исеме | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү хезмәте күрсәтүгә тарифлар, сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01 апрель 2014 ел - 30 июнь 2014 ел | 01 июль 2014 ел - 31 март 2015 ел | 01 апрель 2015 ел - 30 июнь 2015 ел | 01 июль 2015 ел - 31 март 2016 ел | 01 апрель 2016 ел - 30 июнь 2016 ел | 01 июль 2016 ел - 31 март-2017 ел |
| | Аксубай муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | ҖЧҖ «Благоустройство»* | 108,08 | 108,08 | 108,08 | 115,91 | 115,91 | 115,91 |
| | Актаныш муниципаль районы | | | | | | |
| 2 | МУП «КТК Актаныш полигоны»* | 126,62 | 126,62 | 126,62 | 126,62 | 126,62 | 129,40 |

<*> гадиләштерелгән салым алу системасы кулланыла

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
дәүләт комитетының
14 февраль 2014 ел № 10-5/кс
карарына 2нче кушымта

# Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү өлкәсендә коммуналь комплексы оешмаларының җитештерү программаларының төп күрсәткечләре

| № п/п | Коммуналь комплексы оешмасының исеме | 2014 елның 01 апреленнән алып 2015 елның 31 мартына кадәр | | | | | 2015 елның 01 апреленнән алып 2016 елның 31 мартына кадәр | | | | | 2016 елның 01 апреленнән алып 2017 елның 31 мартына кадәр | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Коммуналь комплексы оешмалары җитештерү программарарының күрсәткечләре, мең куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (ӨБС керми) | Коммуналь комплексы оешмалары җитештерү программарарының күрсәткечләре, мең куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (ӨБС керми) | Коммуналь комплексы оешмалары җитештерү программарарының күрсәткечләре, мең куб.м | | | | Кирәкле тулай керем, мең сум. (ӨБС керми) |
| | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү күләме, шул исәптән: | | | | |
| | | Барлыгы | Халык | Бюджеттагы кулланучылар | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджеттагы кулланучылар | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджеттагы кулланучылар | Башка кулланучылар | |
| 1 | ҖЧҖ «Благоуст-ройство»* | 9,477 | 1,854 | 2,545 | 5,078 | 1024,28 | 9,477 | 1,854 | 2,545 | 5,078 | 1061,38 | 9,477 | 1,854 | 2,545 | 5,078 | 1098,47 |
| 2 | МУП «КТК Актаныш полигоны»* | 16,21 | 9,705 | 2,008 | 4,5 | 2052,43 | 17,44 | 10,530 | 2,257 | 4,65 | 2207,79 | 17,44 | 10,530 | 2,257 | 4,65 | 2232,10 |

<*> өстәмә бәягә салымны түләүчеләр рәтенә керми

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге